| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**30 сентябрь 2022ел** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 2576** |
|---|---|---|

Яшь гаиләләргә торак сатып алуга бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен 2022 елның өченче кварталына Зеленодольск муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының бер квадрат метры бәясенең нормативын билгеләү турында

Яшь гаиләләргә торак алу өчен социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең 10 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 03 октябрендәге «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 888 номерлы карары белән расланган, «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» ярдәмче программаны гамәлгә ашыру кысаларында, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы белән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының бер квадрат метры хакының 2022 елның өченче кварталына яшь гаиләләргә торак сатып алуга бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен нормативны 115 859 (йөз унбиш мең сигез йөз илле) сум күләмендә билгеләргә.
2. Зеленодольск муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарны контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче И.Р. Ганиев